**ГЛАВА ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Ямашурма, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмә авылы, Совет ур.,5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**23 ноябрь 2021ел** **№2**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Уставын һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22.10.2009 ел, № 134 карар (Советның 07.02.2020 ел, 19.10.2020 ел, №7 карарлары редакциясендә), Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 3 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 елның 3 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2021 елның 3 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Ямаширмә авылында яшәүчеләр Исемлеге халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүленгән:

а) беренче этап-Гагарин, 1 Май, Яңа, Яшел, Ленин, Марс урамнарында яшәүчеләр;

б) икенче этап-Вахитов, каен, Ключевая, М. Җәлил, Татарстан урамнарында яшәүчеләр

в) өченче этап - кыр, Яшьләр, Тукай, Нариманов, Совет, Мәктәп, Киров, Крайняя урамнарында яшәүчеләр;

5. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Биектау районының Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1)Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын, урам тренажерлары, яктырткычлар сатып алу);

2)Ямаширмә авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм җәю, кышкы юлларны карап тоту: трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту);

3)Ямаширмә авылын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм карап тоту (торбалар сатып алу һәм салу);

4) янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәт хакы).

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

7. Карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.К.Мөхтәрев